**Тема:** “Сабыр төбе- сары алтын”

**Максат:**
1. Укучыларны “Сабыр төбе- сары алтын” дигән темага уйланырга мәҗбүр итеп, тормышта авырлыкларга түзеп, аларны җинеп чыгарга ярдәм итү.
2. Укучыларның үз фикерләрен ачык, матур итеп башкаларга җиткерә, дәлилләп күрсәтә белүләренә ирешү.
3. Укучыларда сабырлык сыйфатын, кешеләргә карата мәхәббәт, ихтирам хисе тәрбияләү.

**Дәреснең көтелгән нәтиҗәсе:**
- Сабыр итә белгән кеше үзенең бөтен максатларына ирешер икәнең белү.
- Нәркем үз- үзендә сабырлык сыйфатын тәрбияли ала икәнен аңлау һәм шуңа омтылу.
- “Дөреслектә сабыр итүчеләргә хисапсыз (бик күп) әҗерләр бирелер” Раббыбыз әйткән сүзләрнең асылына төшенү. (Зөмәр: 10).

**Эпиграф:**
- ***“Дөреслектә сабыр итүчеләргә хисапсыз (бик күп) әҗерләр бирелер” дигән Раббыбызның сүзләренең асылына төшенү.*** (Коръән. Зөмәр: 10).

**Дереснең барышы**

**I. Уку мәсьәләсен кую.**

- Кечкенә генә әкиятне тыңлагыз, шуннан чыгып, бүгенге дәреснең темасын үзегез әйтеп бирегез.

*- Бервакыт патша үзенең вәкилен күрше король янына җибәрә. Юлда тоткарланып, соңга калдым дип, ул бик ашыгып патша сараена йөгереп керә, сулышы бетеп, аны җибәргән патшаның әйткән сүзен тапшыра башлый:*

*- Безнең патша:“Кара койрыклы ак атыгызны сатып җибәрсәгез иде”,- дип сорады,- әгәрдә сатмасагыз ...”*

*Сүзне тыңлап бөтермичә, король болай дип әйтә башлады: “Бер сүз дә ишетәсем килми. Хуҗаңа җиткер: андый ат миндә юк, әгәрдә булса... “, ләкин әйтеп бөтермичә, бераз уйлап туктап калды.*

*Килгән вәкил сүзне тыңлап бөтермичә, корольның туктап дәшмичә торуын үзенчә аңлап, куркып йөгереп чыга, атка атланып кайта һәм хуҗасына корольның тупас җавабын җиткерә.*

*Шулай итеп, ике патшалык арасында озак еллар дәвам иткән күп кеше канын койдырган сугыш башлана. Ниһаять, байтак югалтулардан соң патшалар дуслашырга уйлыйлар һәм әйтелеп бетермәгән сүзләре турында бер- берсен сораштыралар.*

*Король:“Кара койрыклы ак атыгызны сатып җибәрсәгез иде, әгәрдә сатмасагыз ...” дигән сүз белән нәрсә әйтмәкче идең?”- дигән сорауга: “Икенче төрле атыгызны җибәрегез”,- дигән җавап ала.*

*“Андый ат миндә юк, әгәрдә булса... “,- дигән сүз нәрсә турында иде ул?”- дигән патша сорауна. Король болай диган:“Әгәрдә булса, һиччиксез атымны кадерле күрше патшага җибәрер идем”.*

- Юктан башланган сугыш геройларның нинди сыйфатлары булмаган аркасында килеп чыга? (Сабырлык).

**II. Дәреснең темасын ачыклау.**

- Димәк, бүгенге дәреснең темасы... (Сабырлык турында, “Сабыр төбе- сары алтын”).

**III.Уку мәсьәләсен чишү.**

***1. “Нәрсә ул сабырлык?”- дигән сорауга җавап табу.***

- Нинди кешене сабыр диләр?
- Түзә белгән кешене.
- Сабырлык кайсы вакытта кешегә бик кирәк була?
- Кеше авырганда, берәр эшне башкарганда, дуслар белән аралашканда.
- Сабырлакның капма каршы сыйфат нинди ул?
- Нинди кешегә сабырсыз диләр?
- Әйе, укучылар, кеше сабыр булмаса, эшлисе эшенең мәгънәсенә төшенмичә, ашыгып хата ясый, хәтта төзәтеп булмаслык хаталар ясый, уйламыйча гына җавап бирә.
- Димәк, сабырлык ул түземле булуны, авырлыклар килгәндә үзебез белән идарә итә алуны, ямьсез сүзләр әйтү һәм начар гамәлләрдән кылудан үзебезне тыеп кала алуны аңлата. Түзем кеше нинди авырлыкка да түзеп тора белә.

***2. Төркемнәрдә эшләү.***

**1нче бирем** ***Уен “Мин башлыйм, син дәвам ит”*** (мәкальләрне тәрбияче башлый, укучылар дәвам итә).

- Балалар! Хәзер уен уйнап алыйк! Мәкальләрне мин башлыйм- сез дәвам итәрсез.
- Ашыккан- ашка.. *пешкән.*
- Түземлек тамыры әче, ләкин җимешләре ... *татлы.*
- Сабырлык тауларны ... *тигезли.*
- Көтә белү- уңышның зур ... *сере.*
- Тиз йөгергән кеше зак ... *йөгерә алмый.*
- Бәләкәй эшләрдә түземсез булсаң, зур эшләрне дә ... *эшли алмассың.*
- Сабыр итсәң- ... шатланырсың, ашыксаң- ... *үкенерсең.*
- Сабырлы- солтан, сабырсыз ... *шайтан.*
- Түзгән- тимерне дә ... *эзгән.*

**2нче бирем** ***Карточкада бирелгән сорауга җавап табу.***

- Хәзер сезгә гыйбрәтле өзек тәкъдим итәм.

*- Бер бик тиз кызучан малай дусларын еш кына чакларда үпкәләтә торган булган. Бервакыт әтисе аңа бер тартма кадак биргән һәм ачуы килгән саен, сабыр итеп, капкага берәр кадак кына кагарга киңәш иткән. Беренче көнне малай 37 кадак каккан. Алдагы 3- 4 атнада ул, түзәргә тырышып,*
*каккан кадакларның санын көннән- көнгә киметеп барган, чөнки малайга чүкечне табып, кадак кагып йөрүгә караганда, сабыр итү җиңелрәк булып тыелган.*

*Ниһаять, беркөнне малай көне буена бер кадак та каккмаган. Тартма бушагач, ул тагын әтисе янына киңәшкә килгән. Атасы: “Ә хәзер ачуланасы килгәч, сабыр итеп булган саен, капкадан берәр кадакны тартып алып бар”,- дигән. Байтак вакыт узгач, яшь үсмер тартма яңадан кадак белән тулганы турында әтисенә әйткән.*

*Атасы малаен капка янына алып килә һәм: “Улым, син сабыр итәргә өйрәндең, ләкин кара әле бу капкага- ул бекайчанда элекке шикелле булмас. Нәкъ шулай ук кешене*

*үпкәләткәндә, син аның күңелендә мәңге бетмәс җәрәхәт* ***ясыйсың.*** *Күпме гафу үтенсәң дә, яра тезәлми",- дип әйткән.*
- Нәр төркем карточкадагы (тактадагы) биремне эшли.
<u>1 төркем:</u> Хикәяне тыңлагач, аңың темасын (нәрсә турында язылганын) ачыклый торган исем кушыгыз. Бу сыйфат кешегә бик кирәк булган очракларның мисалларын китерегез (авырганда, гыйлем алганда, эш башкарганда, кешеләр белән аралашканда).
<u>2 төркем:</u> Хикәяне тыңлагач, аңың төп фикерен (идея) ачыклый торган исем кушыгыз. (Кешеләр белән тату буласың килсә- сабырлыкка өйрән). Сабырсызлык кешене авыр хәлдә калдыру турында мисаллар китерегез.
<u>3 төркем:</u> Малайга нинди үгет- нәсыйхәт бирер идегез? (Сабыр булырга өйрәнергә, үз- үзеңне тәрбияләргә, дусларның кадерен белергә, ата- ананың киңәшенә колак салырга, кешеләрне рәнҗетүдән ерак булыга).

**Знче бирем.** "Алдагы риваяттән нинди гыйбрәтләр алып була?" дигән сорауга җавап бирү.
- Бу риваяттән нинди гыйбрәтләр алып була (нәтиҗә ясарга)?
/Укучылар җавабы/:
- *Кешене үпкәләткәндә, рәнҗеткәндә аның күңелендә мәңге бетмәс җәрәхәт кала.*
- *Күпме гафу үтенсәң дә, яра тезәлми.*
- *Нәркем үз- үзендә сабырлык сыйфатын тәрбияли ала.*

**3. Сабырлыкның төрләре.**
- ***Кайгы- хәсрәтләргә, һәлакәтләргә түземлек.***

Әгәр хәсрәтләр кешенең малына, җанына, баласына төшсә, ә кешенең бу бәхетсезлекне туктатырга кече җитмәсә, ул вакытта риза булып сабыр итәргә кирәк. Зилзилә, көчле су ташулар, сугышлар вакытында килгән авырлыкларга чыдау- сабырлык билгеседер. Сабырның савабына ышанмаганнар бәхетсезлекләр килгәндә өметсезлеккә төшәләр, яшәүнең ямен югалталар.
- ***Дуслар белән, чит кешеләр белән аралашканда, гаилә тормышында кирәкле түземлек.***

Дуслар белән, чит кешеләр белән, туганнар белән аралашканда иң кирәкле сыйфатларның берсе- түземлек, сабыр итә белү. Укып киткән ривәят безне кешеләрне рәнҗетүдән сак булырга өйрәтә, чөнки күңел җәрәхәте тактадагы кадак эзе генә түгел- мәңге әрни.
- ***Укуга, берәр эш башкарганга, тормыш максатына ирешүгә, гыйбадәткә түземлек.***

Мәктәптә укыганда, югары уку йортларында гыйлем алганда, авыр яки яңа эшнең нәтиҗәсен күрер эчен түземлек бик кирәк. Александр Суворов, атаклы рус полководец, тумыштан бик начар саулыклы булып туса да, балачактан узен чыныктырып, салкын сулар сибенеп, спорт белән **шыйгөлләнеп**, үз- үзендә тәрбияләгән сабырлык һәм максатчанлык аркасында бик зур нәтиҗәләргә ирешә, дошманнарын дөр калтыраткан танылган генерал була.
- ***Гөнаһ эшләрдән тыелу- сабырлыкның тагын бер төре.***

- Гөнаһ эшләрне санап китик әле. (Алдашу, ялкаулык, урлашу, кешене рәнҗетү, тәмәке тарту, аракы эчү...)
- Гөнаһ эшләрдән тыелу- бәхетле буласы килгән һәр кешенең иң кирәкле эшләрнең берсе.

- Сабырлык- бик көчле корал, ләкин түземлекне да урынында кулланырга кирәк. Хәлебездән килгәнне эшләмәсәк, ялкауланып, юклыкка, наданлыкка, хаксызлыкка риза булып ятсак, бу сабырлык булмас.

**4. Танылган шәхесләргә сүз бирик:**

**-** Танылган шәхесләргә сүз бирик. Бу сүзләрне ничек аңлыйсыз?

- *"Сабыр итә белгән кеше үзенең бөтен максатларына ирешер".*
  /Бенджамин Франклин/
- *"Көчле кеше көрәшкәндә иптәшләрен җиңгән кеше түгел, көчле кеше – ачуы чыккан вакытта сабыр итеп, үз ачуын җиңгән кеше".*

**5. Изге Коръән китабыннан.**

- Аллаһы Тәгалә үзенең китабында, бик күп аятьләрендә "дөнья йорты – сынау йорты" икәнлеге турында әйтеп уза. Шушы әйтелгәннәрнең кайберләрен ишетеп узыйк.

- ***"Һәм, әлбәттә, без сезне сынаячакбыз: Курку һәм ачлык белән маллар, җаннар, җиләк-җимешләр тарлыгы белән. (Сыналган вакытларда) сабыр булучыларны исә шатландыр. Ул сабыр булучыларга берәр авырлык килсә, алар әйтәләр: "Без Аллаһы Тәгаләнеке һәм Аңа кире кайтачакбыз". Шуларга Раббылары тарафыннан ярлыкау һәм мәрхәмәт насыйп булачак, дөреслектә алар туры, дөрес юлда булучылар"*** (Бәкара сүрәсенең 155-157).
- ***"Әллә кешеләр: "Без иман китереп инандык!" – дип әйткәч, аларга авырлык-лар килмәс һәм сыналмаслар дип исәплиләрме?! Аларга кадәр булган кешеләр барысы да сыналды, һәм Аллаһы кайсылары дөрес сөйли һәм кайсылары ялганлый икәнен белә бит!"*** (Гәнкәбүт сүрәсе, 2-3 аятләре).

- Аллаһы Тәгалә китабында шулай дип әйтә:

- ***"Аллаһы беркемгә дә күтәрә алмаган сынаулар йөкләмәс..."*** (Бәкара сүрәсе, 286 аять).

- Ягъни Аллаһ һәр кешегә сынавын хәленә карап бирә, арттырмый да, киметми дә.
Сынау дигән сүзне күп кабатладым. Ни өчен? Чөнки һәрбер сынау бездән сабырлык көтә һәм сынауларга сабырлык белән генә каршы торып була.

**6. Эпиграф белән эш.**

- ***"Дөреслектә сабыр итүчеләргә хисапсыз (бик күп) әҗерләр бирелер"*** (Зөмәр: 10).

- Бу сүзләрне бүгенге дәреснең эпиграфы итеп тактага яздык. Җөмләне хор белән кабатлыйк һәм үзебезнең йөрәкләребезгә гомер буена салыйк, беркайчанда онытмыйк. Хор белән укыйлар.

- Җөмләне дәвам итеп карыйк: *"Дөреслектә сабыр итүчеләргә хисапсыз (бик күп) әҗерләр бирелер"*, чөнки..." (... чөнки ул Аллаһының сынауларына сабыр итте: авырса да, якын кешесе үлсә дә, аны үпкәләтсәләр дә Раббыбыз аңа биргән язмышына риза булган).

**7. Хәдисләр.**

- Пәйгамбәребез галәйһиссәламнән шундый хәдис риваять итеlә:

- *"Аллаһы Тәгалә әйтә: "Берәр бәндәмә авырлык килсә һәм шушы вакытта ул, Миңа сыену чараларын эзләп, Миңа ялварса, һичшиксез, Мин аңа сораганчы ук бирермен, һәм догасын кылыр алдыннан ук догасына җавап кайтарырмын. Ә инде бәндәмә авырлык килгәннән соң, Мине онытып башка берәүгә сыгынса, алардан чаралар*

*эзләсә, күк ишекләрен ябармын", ягъни ул бернинди яхшы нәтиҗәгә ирешә алмас."*

- Башка бер хәдисендә Пәйгамбәребез галәйһиссәлам:

- *"Кем берәр төнне авырып уздырса һәм үзенең хәленә сабыр булса, Аллаһтан разый булса, газиз әнисеннән туган көнне гөнаһсыз булган кебек гөнаһларыннан пакьләнер. Әгәр авырсагыз, сәламәтлек сорамагыз", –дип әйткән.*

- Ягъни Пәйгамбәребезнең (с.г.в.)нең соңгы җөмләсендәге сүзнең мәгънәсе шулайрак: *"Әгәр авырган вакытыгызда гөнаһларыгыздан пакьлану һәм Аллаһ Тәгалә каршысына нинди бөек дәрәҗәләргә ирешүвегезне белсәгез, сәламәтлек сорамас идегез. Ләкин бәндә буларак без тынычлык һәм сәламәтлек телибез".*

- Сабырлык үрнәге буларак, *Әюп галәйһиссәламнең тормышын искә төшереп узыйк.* Аллаһы Тәгалә Үзенең китабында аның турында:

***"Без аны сабыр итүче дип таптык. Хакыйкатьтә ул – Аллаһка тәүбә белән кайтучы, күркәм коллардан булды!"*** (Сад сүрәсе, 44 аять).

- Әюп галәйһиссәлам үзенең халкына пәйгамбәр булып җибәрелгән иде, һәм Аллаһ Тәгалә аны бәлки башка пәйгамбәрләрне сынамаган сынаулар белән сынады. Әюп галәй-һиссәламнең мул җимеш бакчалары, балалары, хатыннары һәм һич тә борчымый торган сәламәтлеге бар иде. Муллыгына карамастан, Аллаһы Тәгалә аның өстенә йөкләгән бөтеп эшләрне Әюп галәйһиссәлам кимчелек китермичә, ялкаулык күрсәтмичә, җиренә җиткереп үтәп бара иде. Көннәр үтә торгач, Әюп галәйһиссәламгә сынаулар килә башлады. Иң беренчесе – җимеш бакчасы уңыш бирмичә, бакчасындагы бөтен агачлары һәлак булды. Шайтан аның янына килеп: "Ташла гыйбадәтеңне, бераз үзеңне кайгырт", –дип әйтте.

Бу сүзләрне ишеткәч, Әюп галәйһиссәлам: "Без Аллаһныкы һәм аңа кайтачакбыз. Ул үзе бирде, үзе алды, биргән әйберен кире алганы өчен, мин ничек итеп Аңа ачуланыйм?!" –дип әйтте һәм шайтанны куып җибәрде. Ләкин Әюп галәйһиссәламнең сынаулары моның белән бетмәде. Берсе артыннан берсе, газиз балалары төрле сәбәпләр белән үлә башлады, һәм иң соңында бөтен балалары үлде. Шайтан янәдән кеше сурәтендә аның янына килде: "Әй Әюп, мин кызганам сине, бакчаларың һәлак булды, таянычың булган балаларың үлеп бетте, ә син һаман да Аллаһ, Аллаһ дисең. Ташла бу эшне, бераз үзеңнең хәлеңне кайгырт", –дип әйтте.

Шайтанның бу сүзләрен ишеткән Әюп галәйһиссәлам шулай дип җавап кайтарды: "Без Аллаһныкы һәм аңа кайтачакбыз. Ул үзе бирде, үзе алды, биргән әйберен кире алганы өчен, мин ничек итеп Аңа ачуланыйм?!", – дип шайтанны куып җибәрде. Бу сынаудан соң, Аллаһы Тәгалә Әюп галәһһиссәламнең сәламәтлеген алды, авыруы көннән-көн арта иде, янында хатыныннан тыш беркем калмады. Әюпнең авылдашлары әйтәләр: "Әй Әюп, зәһәр авыруың безгә иярмәсен өчен, авылдан чыгып кит". Әюп галәйһиссәлам туган, үскән, яшәгән авылыннан хатыны белән чыгып китә һәм авылдан бик ерак булмаган бер җиргә барып урнаша. Әюпнең хатыны авылга барып, аннан ризык алып килә иде.

Авыруы көннән-көн көчәйде. Шайтан тагын кеше сурәтендә Әюп галәйһиссәлам янына килеп җитә. Һәм аңа: "Әй Әюп, мин синең хәлеңә хәйран калам, бакчаларың, җиләк-җимешләрең юк, балаларың үлеп бетте, Аллаһы Тәгаләң сиңа авыру бирде, сине авылыңнан чыгардылар, хатының кулына калдың, ә син һаман да Аллаһны мактыйсың. Ташла бу эшеңне, оныт ул Аллаһны", – дип әйтә. Әюп галәйһиссәлам:

"Без Аллаһныкы һәм Аңа кайтачакбыз. Ул үзе бирде, үзе алды", –дип әйтте. Шайтан бу сүзләрне Әюп галәйһиссәлам янына килгән саен ишетте һәм өметсезләнеп аның яныннан китеп барды.

Әюп галәйһиссәлам торып гыйбадәтен үти алмый башлагач кына, кулларын күтәреп АллаһыТәгаләгә ялварды: *"Әй мәрхәмәтлеләрнең иң мәрхәмәтлесе! Миңа авырлык кагылып китте"* (Әл-Әнбия сүрәсе, 83 аять). Ягъни башка төрле сүзләр белән әйткәндә: "Әй Раббым, торып гыйбадәт итә алырлык сәламәтлек насыйп ит миңа", –дип әйтте. Шушы догасыннан соң бөтен сынауларга каршы сабыр, түземле булганы өчен,

АллаһыТәгалә догасын кабул итте һәм җимеш бакчаларын, балаларын, сәламәтлеген, хатыннарын, дәрәҗәсен ике тапкыр арттырып кире кайтарды. Әюп галәйһиссәлам дөньяда дөнья хөрмәтенә, ахирәттә ахирәт бәхетенә иреште.

- Әюп галәһһиссәламнең сабырлык, түземлек мисаллары барыбызга да үрнәк булса иде. Нинди генә хәлдә булсак та, Әюпнең әйткән сүзләрен бер дә онытмыйк:

- Ягъни "Без Аллаһныкы һәм Аңа кайтачакбыз" дигән сүзләрне һәрвакыт исебездә тотыйк. Сабырлыкка багышланган вәгазьне Пәйгамбәребезнең бер хәдисе белән төгәлләргә телим:

- ***"Мөэмин кешенең хәле бик гаҗәпләндерүче, аның бөтен хәлләре аңа яхшылык китерүче, һәм бу өстенлек фәкать мөэмингә генә насыйп була. Әгәр дә аңа берәр шатлык килсә – шөкер итә һәм ул аңа хәерле була. Берәр авырлык килсә – сабыр итә һәм ул аңа хәерле була",*** – дип әйтте Пәйгамбәребез (с.г.в.), *ягъни без мөселманнарга берәр шатлык, сөенеч килсә, Аллаһы Тәгаләгә рәхмәт әйтәбез һәм ул сөенеч ике өлеш артыграк була, ә инде берәр авырлык килсә, сабыр итәбез, Аллаһы Тәгаләдән түземлек сорыйбыз һәм ул авырлык киләчәктә безнең өчен сөенеч җимешенә әйләнә.*

- Сабырлык булсын безнең калканыбыз, сабырлык булсын безнең коралыбыз, сабырлык булсын безгә дөньяда һәм ахирәт бәхетенә юл күрсәтүче дустыбыз.

**V. Рефлексия (Йомгаклау).**

**-** Дәреснең темасын искә тешерегез.

- "Сабыр төбе- сары алтын".

- Бу сүзләрне ничек аңлыйсыз?

- Сабырлык турында дәрестә нәрсе белдегез?

- Сабырлык кешедә тумыштан була, яки тәрбияләнәме?

- Үзегез өчен нинди нәтиҗә ясадыгыз? *(Сабыр итә белгән кеше үзенең бөтен максатларына ирешер).*

- Бу сүзләрне бүгенге дәреснең эпиграфы итеп тактага яздык. Җөмләне хор белән кабатлыйк һәм үзебезнең йөрәкләребезгә гомер буена салыйк, беркайчанда онытмыйк. Хор белән укыйлар.

- Җөмләне дәвам итеп карыйк: "Сабыр итә белгән кеше үзенең бөтен максатларына ирешер, чөнки..." (... чөнки сабыр кеше башлаган эшен ташламый, авырдыкларга түзә, Аллаһның рәхмәтен алып максатына ирешә).

- Бугенге дәрестән нинди гыйбрәтләр алып була (нәтиҗә ясарга)?

*- Кешене үпкәләткәндә, рәнҗеткәндә аның күңелендә мәңге бетмәс җәрәхәт кала.*

*- Күпме гафу үтенсәң дә, яра тезәлми.*

*- Нәркем үз- үзендә сабырлык сыйфатын тәрбияли ала.*

**V. Өй эше.**

- Нәселегезнең сабыр, түземле кешеләрен бел. Алар турында сөйләргә өйрән.